**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 14 ноябре** **№ 92**

**2018 елның 27 апрелендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 66 номерлы карарына үзгәрешләр керту турында**

(*Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 июнендәге 73 номерлы Карары белән кертелгән үзгәрешләр белән*)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контрольисәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 182нче карарына үзгәрешләр кертү хакында” 940нчы номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында” 66нчы номерлы карарына (*Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 июнендәге 73 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән*) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) “Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайлау, вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү” 2нче булегенең 1 пунктының бишенче абзацындагы “4,65” саннарын “6,72” саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге Карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” рәсми сайтының мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Бортас авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге**
**Советы Рәисе Р.С. Сәгдиев**